КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1251

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 октябрь, 913 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен (алга таба – Дәүләт йөкләмәсе);

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең тиешле эшчәнлек өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне минималь-

ләштерүдә чагылдырыла торган, дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төбәк төрләре буенча «А» төркеменә керә торган төп күрсәткечләре исемлеген.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа $4^1$ нче пункт өстәргә:

«$4^1$. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

2020 елның 30 апреленә кадәр контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең «А» төркеменә керә торган төп күрсәткечләре паспортларын расларга;

ел саен, 1 декабрьгә кадәр, контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең «А» төркеменә керә торган төп күрсәткечләре паспортларын актуальләштерүне тәэмин итәргә.»;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсендә:

«Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» бүлегенең 5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5. | Татарстан Республикасындагы музейларның гомуми саныннан музей фонды предметларының сакланышы (иминлеге) шартлары тәэмин ителә торган музейларның өлеше арту, процент (А.3 төркеме күрсәткече) | еллык | ≥ 6 | ≥ 12 | Х | Х | Х | ≥ 6 | ≥ 6,2 | ≥ 6,4»; |

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^3$ нче пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «$6^1$. | 100 мең кешегә гадәттән тыш хәлләрдә һәлак булган кешеләр санын киметү, кеше (А.1.1 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | 0,11 | 0,11 | 0,11 |
| $6^2$. | 100 мең кешегә гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән кешеләр санын киметү, кеше (А.1.2 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | 0,13 | 0,13 | 0,13 |
| $6^3$. | Татарстан Республикасының тулаем төбәк продуктына карата гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән матди зыянны киметү, млн.сум (А.1.3 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | 0,00031 | 0,0003 | 0,0003»; |

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» бүлегенең 11 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «11. | План белән билгеләнгән хезмәт күрсәтүләрнең гомуми саныннан социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты стандартлары таләпләре нигезендә күрсәтелгән социаль хезмәт күрсәтүләр өлеше, процент (А.3 төркеме күрсәткече) | еллык | ≥ 80 | ≥ 85 | Х | Х | Х | ≥ 90 | ≥ 90 | ≥ 91»; |

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы» бүлегенең 6 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6. | Үткән елга карата җитештерү һәм куллану калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру аркасында пычранган җир кишәрлекләре өлешен киметү, процент (А.3 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | 25 | 23,5 | 22»; |

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе» бүлегендә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | Бетерү өчен контроль (күзәтчелек) төре юнәлдерелгән тискәре зыян салулар килеп чыгу аркасында 100 мең кешегә һәлак булучыларның булмавы, кеше (А.1.1 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | 0 | 0 | 0»; |

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «$2^1$. | Бетерү өчен контроль (күзәтчелек) төре юнәлдерелгән тискәре зыян салулар килеп чыгу аркасында 100 мең кешегә сәламәтлегенә уртача авырлыкта зыян (зарар) алган гражданнар саны, кеше (А.1.2 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | ≤ 0,03 | ≤ 0,03 | ≤ 0,03»; |

«Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе» бүлегендә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | База (2015) елына балигъ булган халыкның җан башына алкогольле продукцияне (сырадан тыш) легаль төстә ваклап сатуны киметүне булдырмау, литр (А.3 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | ≥ 18,18 | ≥ 18,18 | ≥ 18,18»; |

3 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга;

«Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе» бүлегендә:

3 һәм 4 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. | Өлешләп төзү объектларының гомуми санына өлешләп төзүнең проблемалы объектлары өлешен киметү (2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы гамәлдә булуы туктатылган аерым муниципаль берәмлекләрдә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроленә (күзәтчелегенә) карата), процент (А.3.1 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | ≤ 14,8 | ≤ 14,6 | ≤ 14,4 |
| 4. | Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата таләпләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирелгән капиталь төзелеш объектларының гомуми саныннан дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы гамәле (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә капиталь төзелеш объектын эксплуатацияләүнең гарантия вакыты эчендә булган капиталь төзелеш объектларындагы авария хәлләренең ачыкланган фактлары өлешен киметү, процент (А.3.2 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | ≤ 4,99 | ≤ 4,98 | ≤ 4,97»; |

5 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга;

«Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты» бүлегенең 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1. | Федераль, төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының гомуми санында канәгатьләнерлек хәлдә булган мәдәни мирас объектлары өлеше арту, процент (А.3 төркеме күрсәткече) | квар-тал | Х | Х | 35,3 | 35,35 | 35,4 | 35,5 | 35,7 | 35,9»; |

«Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе» бүлегенең 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | Эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозып эксплуатацияләнә торган үзйөрешле машиналар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре аркасында һәлак булучылар өлешен киметү, процент (А.1 төркеме күрсәткече) | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | ≤ 24,5 | ≤ 24 | ≤ 23,5»; |

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең тиешле эшчәнлек өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне минимальләштерүдә чагылдырыла торган, дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төбәк төрләре буенча «А» төркеменә керә торган төп күрсәткечләре исемлеген (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 27 декабрь, 1244 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 декабрь, 1251 нче
карары редакциясендә)

Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең тиешле эшчәнлек өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне минимальләштерүдә чагылдырыла торган, дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төбәк төрләре буенча «А» төркеменә керә торган төп күрсәткечләре исемлеге

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы:

Россия Федерациясе Музей фондының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт өлеше торышына дәүләт контроле.

А.3 күрсәткече. Татарстан Республикасындагы музейларның гомуми саныннан музей фонды предметларының сакланышы (иминлеге) шартлары тәэмин ителә торган музейларның өлеше арту, процент.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы:

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге.

А.1.1 күрсәткече. 100 мең кешегә гадәттән тыш хәлләрдә һәлак булган кешеләр санын киметү, кеше.

А.1.2 күрсәткече. 100 мең кешегә гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән кешеләр санын киметү, кеше.

А.1.3 күрсәткече. Татарстан Республикасының тулаем региональ продуктына карата гадәттән тыш хәлләр аркасында китерелгән матди зыянны киметү, млн.сум.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы:

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дәүләт контроле (күзәтчелеге).

А.3 күрсәткече. План белән билгеләнгән хезмәт күрсәтүләрнең гомуми саныннан социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты стандартлары таләпләре нигезендә күрсәтелгән социаль хезмәтләр өлеше, процент.

4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы:

Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге.

А.3 күрсәткече. Үткән елга карата җитештерү һәм куллану калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру аркасында пычранган җир кишәрлекләре өлешен киметү, процент.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе:

Татарстан Республикасында төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге.

А.1.1 күрсәткече. Бетерү өчен контроль (күзәтчелек) төре юнәлдерелгән тискәре зыян салулар килеп чыгу аркасында 100 мең кешегә һәлак булучыларның булмавы, кеше.

А.1.2 күрсәткече. Бетерү өчен контроль (күзәтчелек) төре юнәлдерелгән тискәре зыян салулар килеп чыгу аркасында 100 мең кешегә сәламәтлегенә уртача авырлыкта зыян (зарар) алган гражданнар саны, кеше.

6. Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе:

Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге).

А.3 күрсәткече. База (2015) елына балигъ булган халыкның җан башына алкогольле продукцияне (сырадан тыш) легаль төстә ваклап сатуны киметүне булдырмау, литр.

7. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе:

Өлешләп төзү өлкәсендә төбәк контроле (күзәтчелеге).

А.3.1 күрсәткече. Өлешләп төзү объектлары-ның гомуми санына өлешләп төзүнең проблемалы объектлары өлешен киметү (2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы гамәлдә булуы туктатылган аерым муниципаль берәмлекләрдә күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроленә (күзәтчелегенә) карата), процент.

Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге.

А.3.2 күрсәткече. Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата таләпләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирелгән капиталь төзелеш объектларының гомуми саныннан дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы гамәле (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә капиталь төзелеш объектын эксплуатацияләүнең гарантия вакыты эчендә булган капиталь төзелеш объектларындагы авария хәлләренең ачыкланган фактлары өлешен киметү, процент.

8. Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышы, аларны карап тоту,

саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы буенча төбәк дәүләт күзәтчелеге.

А.3 күрсәткече. Федераль, төбәк һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының гомуми санында канәгатьләнерлек хәлдә булган мәдәни мирас объектлары өлеше арту, процент.

9. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе:

Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренең техник торышы өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге.

А.1 күрсәткече. Эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозып эксплуатацияләнә торган үзйөрешле машиналар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре аркасында һәлак булучылар өлешен киметү, процент.